ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28 июня 2016 г.**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 1679**

Зеленодольск шәһәре, Тургенев урамы, 13 нче йорт адресындагы җир кишәрлегендә һәм анда урнашкан күчемсез милек корылмаларын алу турында

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 26.09.2013 ел, №2178 карары белән расланган 2013-2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатыннан чыгып, 21.07.2007 ел, №185-ФЗ «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд турында» Федераль закон, Торак, Җир кодекслары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре, Тургенев ур., 13 нче йорт адресы буенча, Тургенев урамы 13 нче номерлы күпфатирлы торак йорт, шулай ук кушымта булып бирелә торган исемлек нигезендә, күрсәтелгән йортның җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез милек корылмаларын (торак һәм торак булмаган биналар) муниципаль ихтыяҗлар өчен алырга.
(кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайты составында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:
- алына торган күчемсез милек хокукына ия булучыларга;
- күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;
- МКУ «Торак сәясәте департаменты» на җибәрергә.

4. МУ «Зеленодольск муниципаль районының Мөлкәт һәм Җир мөнәсәбәтләре палатасы» әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә тиеш.

5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 03.12.2015 ел, №2626 карары нигезендә Зеленодольск шәһәре Тургенев урамындагы кадастр номеры (яки шартлы) 16:49:010506:711 булган 13 нче йорттагы 1 нче бүлмәне, 2 нче бүлмәне, 1 нче фатирны алу турындагы карарның үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сахибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
28.06.2016 ел №1679

Авария хәлендә табылган һәм сүтелергә тиешле, Тургенев урамы, 13 нче номерлы күпфатирлы торак йортта урнашкан алынырга тиешле күчемсез милек корылмалары (торак һәм торак булмаган бүлмәләр)
ИСЕМЛЕГЕ

| Квартира номеры | бүлмәләр | Кадастр яки корылманың шартлы номеры |
|---|---|---|
| 1 | 1, 2 | 16:49:010506:711 |